КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 23 гыйнвар г.Казань № 31

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт финансларын савыктыру чаралары планын раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1194 нче карары белән расланган 2024 елга кадәрге чорга Татарстан Республикасы дәүләт финансларын савыктыру чаралары планына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт финансларын савыктыру чаралары планын раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1194 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 14 гыйнвар, 8 нче; 2013 ел, 30 сентябрь, 701 нче; 2015 ел, 9 февраль, 74 нче; 2017 ел, 8 ноябрь, 849 нчы; 2018 ел, 20 февраль, 97 нче; 2019 ел, 18 декабрь, 1161 нче; 2020 ел, 29 июнь, 541 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2024 елга кадәрге чорга Татарстан Республикасы дәүләт финансларын савыктыру чаралары планына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты керемнәре артуга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашырудан бюджет эффекты, мең сум» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты керемнәре артуга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашырудан бюджет эффекты, мең сум | 3 198 642,5* | 4 926 507,8* | 990 826,8* | 1 681 318,8* | 854 780,0** | 776 730,0** | 766 730,0**»; |

«Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты чыгымнарын оптимальләштерү программасын гамәлгә ашырудан бюджет эффекты, мең сум» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты чыгымнарын оптимальләштерү программасын гамәлгә ашырудан бюджет эффекты, мең сум | 8 832 807,9* | 7 761 070,6* | 5 249 972,6* | 6 839 749,1* | 5 409 307,0** | 5 623 343,9** | 5 845 942,3**»; |

3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «3. Татарстан Республикасы дәүләт бурычын киметүгә юнәлдерелгән чаралар*** | | | | | | | | | | |
| 3.1. | Федераль бюджеттан бирелгән бюджет кредитлары буенча бурычларны каплау йөкләмәләрен үз вакытында үтәү (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 19 октябрендәге 1704 номерлы һәм 2021 елның 12 октябрендәге 1740 номерлы карарларын гамәлгә ашыру кысаларында бюджет кредитлары буенча Россия Федерациясе алдындагы Татарстан Республикасы бурычын исәптән төшерүне исәпкә алып) | Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы | ел саен | федераль бюджеттан бюджет кредитлары буенча Татарстан Республикасының бурыч йөкләмәләре буенча үз вакытында түләнмәгән бурыч күләме, млрд.сум | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 3.2. | Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау өчен кредит оешмаларыннан, чит ил банкларыннан һәм халыкара финанс оешмаларыннан дәүләт кыйммәтле кәгазьләрен һәм кредитларны файдаланмау | Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы | даими | хисап елыннан соң килә торган елның 1 гыйнвары хәленә карата Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау өчен кредит оешмаларыннан, чит ил банкларыннан һәм халыкара финанс оешмаларыннан дәүләт кыйммәтле кәгазьләре һәм кредитлар буенча йөкләмәләр рәвешендә Татарстан Республикасы дәүләт бурычы күләме, млрд.сум | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 3.3. | Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләрен бирү күләмен чикләү | Татарстан | даими | хисап елыннан соң килә торган елның 1 гыйнварына Та- | ≤10,5 | ≤10,3 | ≤10,0 | ≤10,0 | ≤10,0 | ≤10,0 | ≤10,0 |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Республикасы Финанс министрлыгы | | тарстан Республикасының бирелгән дәүләт гарантияләре буенча йөкләмәләр күләменең хисап финанс елында Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең гомуми еллык күләменә карата нисбәте (кире кайтарылмый торган керемнәр күләмнәрен исәпкә алмыйча), процент | | | | | | | |
| 3.4. | Гарантия очрагы килеп чыгу рискын киметү максатларында Татарстан Республикасының бирелгән дәүләт гарантияләре буенча гарантияләр алучылар белән эшләү | Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы | даими | Татарстан Республикасы үтәлгән дәүләт гарантияләре күләме, млн.сум | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| Татарстан Республикасының дәүләт бурычын киметүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашырудан бюджет эффекты***, мең сум | | | | | 24,0* | 287,3* | 261,4* | 24,3* | 286,6** | 1 741,2** | 1 821,2**»; |

түбәндәге эчтәлекле «***» астөшермә өстәргә:

«***Инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү өчен Россия Федерациясе субъекты бюджетына федераль бюджеттан бирелә торган бюджет кредитларын исәпкә алмыйча.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин